**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«08» декабрь 2025 ел　　　　Күзкәй авылы　　　　№ 2/4

**Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләрнең хезмәтенә түләү турында нигезләмәне раслау хакында**

«Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында» РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 статьясы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының граждан персоналы (хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү системасы турында» Россия Федерациясе Оборона министрының 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы, авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советының хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләрнең хезмәтенә түләү турында нигезләмәне расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советының хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләрнең хезмәтенә түләү турында нигезләмә» Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советының 2023 елның 30 мартындагы 2/4 номерлы карары.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы　　　　Э.Р. Гәрәев

Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Советының 2025 елның 08 декабрендәге 2/4 номерлы карарына кушымта

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәп буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирлекнең хәрби-исәп хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибен көйли.

2. Хәрби-хисап хезмәткәренә хезмәт өчен түләү фонды, федераль бюджеттан авылга тапшырыла торган субвенцияләр күләменнән чыгып, календарь елга формалаша.

3. Өстәмәләр күләме хезмәт өчен түләүгә бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә билгеләнә.

## II. Хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпне гамәлгә ашыручы белгечләрнең хезмәтенә түләү әлеге Нигезләмә нигезендә башкарыла һәм айлык вазыйфа окладыннан (алга таба – вазыйфа оклады), компенсация түләүләреннән һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән тора.

2. Һөнәрләрне бергә башкарган хәрби-исәп хезмәткәрләре өчен хәрби исәптә торучы гражданнар санына туры пропорциональ рәвештә сәгать атнасы билгеләнә.

3. Хәрби- исәп хезмәткәренең вазыйфаи оклады күләмен бүлекчәсе башлыгы ярдәмчесе окладына тиңләштерелгән окладтан «Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының граждан персоналы (хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү системасы турында» РФ оборона министрының 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы нигезендә билгеләргә.

Вазыйфа оклады күләме, сум

Бүлекчә башлыгы ярдәмчесе 11030,00.

Хезмәт хакына карата «Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының граждан персоналы (хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү системасы турында» РФ оборона министрының 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы өчен хезмәт хакына карата 1,15 тәшкил иткән коэффициент кулланыла.

4. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы карары белән расланган Хәрби исәп турында нигезләмәнең 11 пункты нигезендә җирле үзидарә органнарында хәрби исәпне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр саны түбәндәге нормаларны исәпкә алып билгеләнә:

- һөнәрләрне бергә башкаручы 1 хезмәткәр – хәрби исәптә 500дән азрак граждан булганда;
- 1 азат ителгән хезмәткәр – хәрби исәптә 500дән 1000гә кадәр граждан булганда;
- хәрби исәптә торучы һәр 1000 гражданга 1 азат ителгән хезмәткәр.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 282, 284, 285 статьялары нигезендә һөнәрләрне бергә башкарган хәрби-исәп хезмәткәренең вазыйфа окладының максималь күләме азат ителгән хәрби- исәп хезмәткәренең вазыйфа окладының 50%ыннан артмаска тиеш. Һөнәрләрне бергә башкарган хәрби- исәп хезмәткәренә,

хәрби исәптә торучы гражданнар санын исәпкә алып, түбәндәге вазыйфа окладлары билгеләнә:

- хәрби исәптә 400гә кадәр граждан булганда – азат ителгән хәрби-хисап хезмәткәренең вазыйфа окладыннан 40%;

- хәрби исәптә 401дән 500гә кадәр граждан булганда – азат ителгән хәрби-хисап хезмәткәренең вазыйфа окладыннан 50%.

5. Хезмәткәргә түбәндәге түләүләр башкарыла:

а) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфа окладына түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә:

1 елдан артык - 5 процент;
2 елдан артык - 10 процент;
3 елдан артык - 15 процент;
5 елдан артык - 20 процент;
10 елдан артык - 30 процент;
15 елдан артык - 40 процент.

Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә билгеләү хокукын бирә торган эш стажын исәпләгәндә исәпкә алына торган чорлар календарь исәпләүдә билгеләнә һәм кушыла. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә алу хокукын бирә торган эш (хезмәт) стажын билгеләү өчен төп документ булып хезмәт кенәгәсе (хәрби билет) тора. Эш (хезмәт) стажын раслап, шулай ук тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү алуга хокук бирә торган эш (хезмәт) стажы булуын раслый торган башка документлар да тапшырылырга мөмкин. Хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында да тәкъдим ителергә мөмкин.

Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә әлеге өстәмәнең күләмен билгеләү яисә арттыру хокукы барлыкка килгән вакыттан билгеләнә һәм түләнә.

Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә күләмен вакытында яңадан карау өчен җаваплылык кадрлар эше өчен җаваплы хезмәткәргә йөкләнә.

Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмәне билгеләү тиешле хокукый акт белән рәсмиләштерелә;

б) вазыйфаи бурычларны намус белән үтәгән өчен елына ике вазыйфаи окладка кадәр исәбеннән бер мәртәбә акчалата бүләкләү.

Вазыйфаи бурычларны намус белән үтәгән өчен бер тапкыр акчалата бүләкләү авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнергә мөмкин. Ел нәтиҗәләре буенча түләү өчен нигез булып оешма җитәкчесе боерыгы тора;

в) окладка 77% күләмендә айлык премия;

д) федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актларында каралган башка түләүләр (премияләр, матди ярдәм һәм башка кызыксындыру түләүләре) хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә хезмәт өчен түләүнең расланган фонды чикләрендә. Эш нәтиҗәләре буенча премия һәм башка стимуллаштыручы түләүләр оешма җитәкчесе боерыгы нигезендә түләнә.

## III. Хәрби исәп буенча белгечкә ял

Хәрби исәп буенча белгечкә дәвамлылыгы 28 календарь көн булган еллык түләүле отпуск бирелә. Һөнәрләрне бергә башкаручы белгечләр өчен еллык түләүле ял төп эшчәнлек буенча ял белән бер үк вакытта бирелә.